| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 апрель 2014 ел Казан шәһәре № 6-24/тп

***Казан шәһәре “Водоканал” муниципаль унитар предприятиясенең ташландык суларны агызу үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) хезмәте өчен тарифларны билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу” 13 май 2013 ел № 406 Россия Федерациясе карары, “Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 29 июль 2013 ел №644 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны тәртипкә салуда методик киңәшләрне раслау турында” Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 27 декабрь 2013 ел №1746-э боерыгы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган карарына килештереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. Казан шәһәре “Водоканал” муниципаль унитар ташландык суларны агызу үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) хезмәте өчен тарифларны әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.
2. Түбәндәге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар үз көченә кергән көннән 2014 елның 31 декаберенә хәтле үз көченә ия була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына кушымта
18 апрель 2014 ел № 6-24/тп

Казан шәһәре “Водоканал” муниципаль унитар предприятиясенең ташландык суларны агызу үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифлары

| № п/п | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тариф (ӨБС исәпкә алынмаган), коэффициент |
|---|---|---|---|
| 1 | Тоташтыру йөкләнеше өчен база тарифы | Мең сум/ м3 сәг | 4,407 |
| 2 | Челтәрнең озынлыгы тарифы база ставкасы | Мең сум/м | 22,129 |
| 3 | Челтәрнең диаметрына карата тарифның дифференциация коэффициенты: | | |
| 3.1 | 40 мм диаметрлы һәм аннан кече булган | - | - |
| 3.2 | 40 мм - 70 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | - |
| 3.3 | 70 мм - 100 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | - |
| 3.4 | 100 мм - 150 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | 0,43 |
| 3.5 | 150 мм - 200 мм диаметрлы (эченә алып) | - | 0,46 |
| 3.6 | 200 мм - 250 мм диаметрлы (эченә алып) | - | 0,50 |
| 3.7 | 250 мм диаметрлы һәм аннан зурырак булган | - | 0,59 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге